ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

24.10.2020 № 1

На № ____________ от ______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Мулланур Вахитов исемендәге авылда гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 2020нче елның 24нче октябрендә узган «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Мулланур Вахитов исемендәге авылда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы? - Мулланур Вахитов исемендәге авылда су алу җайланмасын санитар саклау зонасын төзекләндерү, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмә төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 176 катнашучы, тавыш бирүдә 105 кеше катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 102 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашкан 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында халык җыены булды, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Мулланур Вахитов исемендәге авылда яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән гражданнарның ташламалы категориясеннән тыш, һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Мулланур Вахитов исемендәге авылында 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә

җибәрүгә ризамы? - Мулланур Вахитов исемендәге авылда су алу җайланмасын санитар саклау зонасын төзекләндерү, дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен халыкка Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авыл мәгълүмат стендларында игълан итергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Кәримов Ф. Р.